ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасына 2026 елда түбәндәгеләрне үткәрүне йөкләргә:

2023 елдан алып 2025 елга кадәр һәм 2026 елның узган чорында заманча (уңайлы) шәһәр мохите булдыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрүне;

2024 елдан алып 2026 елга кадәр чорда Татарстан Республикасында гражданнарга Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга бирелгән дәүләт ярдәме чараларының нәтиҗәлелегенә аудит үткәрүне.

2. Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2026 елның IV кварталында тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 570-VII ДС